**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«26» 12 2022 ел №4206

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең генераль планы проекты белән килешү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясына, «Муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру документлары проектларын килештерү тәртибен, территориаль планлаштыру документлары проектларын килештергәндә, килештерү комиссиясенең составын һәм эш тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе региональ үсеш министрлыгының 2016 елның 21 июлендәге 460 номерлы боерыгына, Тукай муниципаль районы уставына, Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча 2022 елның 21 декабрендәге халык тыңлаулары беркетмәсенә, Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча 2022 елның 21 декабрендәге халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмәгә, килештерү комиссиясенең 2022 елның 25 декабрендәге беркетмәсенә таянып,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «ГК-Групы» ЖЧҖ тарафыннан эшләнгән һәм 2022 елның 21 декабрендә Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең Шилнәбаш авылында халык тыңлауларында каралган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең генераль планы проекты белән килешергә.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең генераль планы проектын, халык тыңлаулары беркетмәсе һәм халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә һәм килештерү комиссиясе беркетмәсе белән, Тукай муниципаль районы Советына раслау өчен юнәлтергә.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хабибуллин